

Мәктәп укучылары җәйге каникулларында укуларыннан рәхәтләнеп ял итәләр.Бу вакыт аерырым истәлекле коннәре белән кадерле. Менә мәктәп ял лагерлары эшләрен тәмамлыйлар инде. Кайда ничегрәк булды сон ул? Шул сорауга берничә торле жавап. Ләмберә районы Аксен мәктәбе беренче сентябрь конне ярты гасырлык юбилеен бәйрәм итәргә жыена. Бу мәктәп кvпләребезгә укучыларынын кvп санлы (бvген - 61) булуы, коллективнын тырыш хезмәте, Альфия Ибригим кызы Бедрединова да vзенен ике дистәдән артык директорлык хезмәте белән педагогиягә зур олеш кертve турында хәбәрдарбыз. Бvген бу белем йортында укучылар рәхәтләнем ял итә. Башлангыч сыйныф укучылары очен «Тосле учлар» белән 4-8 сыйныфлар очен «Патриот» дигән отрядлар бар.

Тыгыз программаларында экскур-сияләрдә ял иттеләр, шигырьләр, жырлар, рәсемнәр ярышында осталыкларын сынадылар, кул эшләре белән сәләтләрен арттырдылар. Ял лагере директоры Фәvзия Фатих кызы Булатова житәкчелегендә Альфия Касим кызы Исмаилова һәм Гульнара Загидулла кызы Трофимова ике дистә бала белән беренче июньгә - Балалар яклау коненә багышлап зур аерым программа буенча тантаналы линейкада хокvмәт байрагын кvтәрv белән чара башланып китте.

Әле генә «Патриот» дигән ял лагере эшен тәмамлады. Исеме эчтәлегенә туры килә; барлык эшләр шул юнәлештә барды. Ана-аталарга балаларынын ир-тәнге 8.30 сәгатьтән алып 16 га кадәр, оч тапкыр ашау белән, торле чараларда катнашулары Саранск яки Большая Елховкага укырга йортvгә караганда кvпкә унай дип таптылар. Теләгән, елан ите ашаган, диләр бездә, андыйлар бар. Алдагы еллардагы бер проблема - тирә-як мәктәпләренә балаларын йортv - бу процесс кими бара. Сонгы вакыт кvп кенә ата-ана балаларынын нәкъ Аксен мәктәбендә белем алуларын тели башладылар. Бvген бу мәктәптә 61 укучы белем ала. Алдагы елларда беренче сыйныфта ике-оч укучы булса, быелгы уку елында бу мәктәпнен беренче сыйныфына укырга ун бала килә. Биредә тәжрибәле педагоглар белем бирv процессын кон таләп иткәнчә, алдынгы технологияләрне кулланып, эш итә. Тәрбия процессы да тиешле дәрәжәгә куелган. Нәтижәдә, бу мәктәп чыгарылыш сыйныф укучылары югары белем йортларынын бюджет бvлекләренә профессия vзләштерергә керәләр.

Жәй, каникуллар, ял... Менә шундый девиз белән Кадошкино районы мәктәбе укучылары да торле мәктәп лагерьларында 12 июльгә кадәр ял иттеләр. Башка мәктәпләр белән бергә, Латыш урта мәктәбендә 35 бала, Большеполянкада 20 бала ял итте. Район мәктәпләреннен 12 активисты очен Латышовкада тагы 15 июльгә кадәр дә ял оештырылган иде. Егерме биш сәләтле укучы очен Кадошкино урта мәктәбе базасында

ял лагере 21 июльгә кадәр дәвам итәр.
Мордовия сәләтле татар балалары очен ел саен Краснослабодск районындагы «Сивинь» җәйге ял лагере базасында «Яшә, туган тел!» этномәдәни регионара сменасы эшли. Оештыручысы – Мордовия республикасы мәгариф министрлыгы. Быел да тел һәм әдәбият, башка ярышларда жинvче балалар ял итә башлады.
Балалар җәйге ял лагерьларында коч жыеп, яна уку елына яна ометләр белән барырга әзерләнәләр.

Н.Хәлил